Татарстан
Республикасы Милли
китапханәсе

# Әдәбият ханы – Әмирхан

Күренекле татар язучысы
Әмирхан Еникинең
115 еллык юбилеена багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2024

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе

# Әдәбият ханы – Әмирхан

Күренекле татар язучысы
Әмирхан Еникинең 115 еллык юбилеена
багышланган методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2024

**УДК 025.5**
**ББК 78.37**
**Ә 26**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият шурасы карары белән басыла

*Төзүчесе З.Ә. Җамалиева*
*Мөхәррире И.Г. Һадиев*

**Ә 26** **Әдәбият ханы – Әмирхан:** күренекле татар язучысы Әмирхан Еникинең 115 еллык юбилеена багышланган методик-библиографик ярдәмлек /Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2024. – 40 б.

Ярдәмлек Әмирхан Еникинең тормыш юлына һәм иҗатына багышланган әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Бирелгән материалларны семинарлар, әдәби кичәләр, фикер алышулар һәм башка мәдәни чаралар үткәрүдә файдаланып була.

**УДК 025.5**
**ББК 78.37**

© Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе, 2024
© «Милли китап» нәшрияты, 2024

# КЕРЕШ СҮЗ

Күренекле язучы Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев 1909 елның 17 февралендә (яңа стиль белән 2 мартта) элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан Республикасының Благовар районы) Яңа Каргалы авылында таза хәлле крестьян гаиләсендә туган. 1911 елда аның әтисе гаиләсе белән Яңа Каргалыдан кырык чакрым ераклыктагы Дәүләкән дигән авылга күченә. Әмирханның балалык һәм мәктәп еллары шул авылда уза.

Яшьтән үк әдәбият, иҗат эше белән кызыксынган Ә.Еники 1925 елның җәендә Казанга килә һәм китап кибетенә курьер булып эшкә урнаша. Бер елдан ул Казан университеты каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы чорда көндәлек матбугат битләрендә аның әдәби парчалары һәм хикәяләре күренә башлый.

1927–1933 еллар арасында Ә.Еники Донбасста – ликбез курсларында укытучы, Казан мех фабрикасында – сортировщик, «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә штаттан тыш хәбәрче хезмәтендә була, бер үк вакытта, төп эшеннән аерылмыйча, 1931–1933 елларда Казанда Хезмәтне фәнни оештыру институтында укый. Шуннан соң ул Ватан сугышына кадәр Казандагы җирле сәнәгать системасында техник укыту буенча методист (1934 –1935), кинофикация трестында инструктор (1935–1936), «Азеркино» (Баку) студиясенең районндагы махсус вәкиле (1936–1937), Казанның 2 нче номерлы тегү фабрикасы каршындагы стахановчылар мәктәбендә (1937–1939) һәм Үзбәкстанның Маргилан шәһәрендәге гомуми белем бирү мәктәпләренең берсендә укытучы булып эшли. 1941–1945 елларда әдип – Ватан сугышы фронтында: хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьләрендә рядовой солдат булып хезмәт итә.

Армиядән кайткач, Ә.Еники берникадәр вакыт «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдәби

хезмәткәр, аннары Татарстан радио комитетында әдәби тапшырулар редакторы булып эшли. 1950–1952 елларда исә Казан авиация техникумында татар теле укыта. 1953 елда ул бөтенләе белән профессиональ язучылык хезмәтенә күчә.

Аерым журналистик язмалары һәм «Дус кеше» (1929), «Пожар» (1929), «Никуличева һәм аның иптәшләре» (1934), «Көзнең бер кичендә» (1939) шикелле повесть, хикәяләре белән сугышка кадәр үк матбугатта исеме күренгәләсә дә, Ә.Еники үзенчәлекле язучы-художник буларак, нигездә, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда формалаша. Аның «Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Бер генә сәгатькә» (1944), «Ялгыз каз» (1944), «Мәк чәчәге» (1944), «Кунакчыл дошман» (1945), «Тауларга карап» (1948), «Кем җырлады» (1956) кебек хикәяләре татар психологик прозасының матур үрнәкләре булып саналырга хаклы. Аларда дәһшәтле сугыш шартларында гади совет кешесенең рухи чыдамлыгы, тыйнаклыгы, юлындагы авырлыкларны батырлык белән кичерүе һәм тормышка, яшәүгә булган тирән ышанычы сәнгатьчә калку итеп сурәтләнә. Әдип, барыннан да элек, сугыш чынбарлыгының кеше рухында, табигате-холкында чагылышын анализлый һәм көндәлек тормыш вакыйгалары, детальләре аша үз геройларының эчке дөньясын, характер үзенчәлекләрен психологик төгәллек белән, тәэсирле итеп ачуга ирешә.

Тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын анализлауда психологик тирәнлеккә омтылу узган гасырның илленче-җитмешенче еллары арасында әдипкә тагын да зуррак иҗади уңышлар алып килә. Язучының «Рәхмәт, иптәшләр!» (1951–1952), «Саз чәчәге» (1955), «Йөрәк сере» (1957), «Рәшә» (1962), «Вөҗдан» (1968), «Без дә солдатлар идек» (1971), «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) исемле повестьлары, «Ялгызлык» (1957), «Туган туфрак» (1959), «Матурлык» (1964), «Төнге тамчылар» (1964), «Әйтелмәгән васыять» (1965), «Курай» (1970), «Тынычлану» (1978)

кебек хикәяләре, кешеләр арасындагы төрле катлаулы мөнәсәбәтләрне реалистик рухта яктыртуы һәм заманны борчыган әхлакый-этик мәсьәләләрне кыю рәвештә күтәрүе белән бергә, сәнгатьчә камил эшләнүләре җәһәтеннән дә аерым игътибарга лаеклар. Геройның күңел серләренә тирән үтеп керә белү осталыгы, фикернең фәлсәфи үткенлеге һәм драматик киеренкелеге, форманың пөхтә һәм җентекле эшләнүе, тел-сурәтләү чараларының төрле стилистик буяуларга, образлы фикерләүдәге милли үзенчәлекләргә бай булуы – болар Ә.Еники талантының төп сыйфатларын тәшкил итәләр.

Ә.Еники иҗатында юмор-сатира, әдәби тәнкыйть, очерк, публицистика, мемуар жанры әсәрләре һәм әдәби тәрҗемәләр дә бик зур урын били. «Күсия ханым», «Күңелсез мәҗлес», «Кунакта», «Бөке», «Сыбызгы» кебек кыска хикәяләрендә ул үткен-җор тел, оста тотып алынган тормыш детальләре ярдәмендә җәмгыятебездә очрый торган кире типларның гомумиләштерелгән сатирик портретларын күз алдына китереп бастыра. Гомумән, юмор-сатира Ә.Еники язу стиленең мөһим хасиятләреннән берсе булып, аның элементлары теге яки бу күләмдә язучының һәрбер әсәрендә диярлек очрый.

Ә.Еникинең иҗтимагый тормыштагы актуаль мәсьәләләргә багышланган публицистик мәкаләләре, очерклары, әдәбият-сәнгать турындагы уйланулары һәм истәлек язмалары, бергә тупланып, 1983 елда аерым китап булып чыга. Сиксәненче еллар башында исә «Казан утлары» журналы битләрендә (1981, №10, 11; 1982, №12; 1985, №1, 2) әдипнең яңа әсәре – автобиографик материалларга нигезләнеп язылган «Соңгы китап» исемле документаль повесте дөнья күрә.

Ә.Еники – әдәби тәрҗемә остасы. Ул украин язучысы О.Гончарның «Знаменосцы» («Байрак йөртүчеләр», 1951) романын, А.Островскийның «Без вины виноватые» («Гаепсез гаеплеләр», 1953) драмасын, М.Бубенновның «Бе-

лая берёза» («Аккаен», 2 нче кисәк, 1954) романын, К.Паустовскийның «Летние дни» («Җәй көннәре», 1960) исемле хикәяләр җыентыгын, Э.Казакевичның «Синяя тетрадь» («Зәңгәр дәфтәр», 1964), Ч.Айтматовның «Беренче мөгаллим» (1965) повестьларын һәм күп кенә СССР халык әкиятләрен татар теленә тәрҗемә итә. Аның үзенең дә төп әсәрләре рус теленә һәм башка милли телләргә тәрҗемә ителгән.

Ә.Еникинең әдәби иҗаты Совет хөкүмәте тарафыннан югары бәяләнә. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы (1979) һәм «Почёт Билгесе» (1957) орденнары белән бүләкләнә. 1984 елда «Юлчы» исеме белән чыккан хикәяләр җыентыгы һәм русча тәрҗемәдә басылган «Повести и рассказы» (1982) китабы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1985 ел, 14 гыйнвар Указы нигезендә ТАССР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Әдипкә 1989 елда «Татарстанның халык язучысы» дигән исем бирелә.

2000 елның 16 февралендә Казанда вафат була, Яңа бистә зиратына җирләнә.

Ә.Еники – 1946 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Әмирхан Еники исеме укучыларга яхшы таныш. Юбилей уңаеннан китапханәләрдә төрле чаралар: семинарлар, конференцияләр, китап күргәзмәләре, әдәби кичәләр, китапларга күзәтү, әдәби әңгәмәләр һәм лекцияләр, викториналар үткәрергә киңәш итәбез. Әмирхан Еникинең тормышы һәм иҗатына багышланган кайбер мәгълүматларны һәм фоторәсемнәрне Интернет челтәреннән алырга мөмкин.

**Интернет-чыганаклар:**

https://kitaphane.tatarstan.ru/tat/eniki.htm Әмирхан Еники. Биобиблиографик белешмәлек

https://belem.ru/node/3697 Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре буенча китап укучылар конференциясе

https://belem.ru/node/1473 Тарханова И.Г. 11 нче татар сыйныфында әдәбият дәресе. Тема: Ә.Еники хикәяләрендә кешеләрнең күңел дөньясын сурәтләү үзенчәлекләре

http://gzalilova.narod.ru/adabiyat_deftere/11-AE.html Әмирхан Еники (1909–2000) (Тормыш баскычлары; Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗаты буенча викторина сораулары)

https://tatkniga.ru/upload/oldbook/pdf/3095.pdf Еники Әмирхан. Әсәрләр. 5 томда. 1 нче том

https://sptatar.com/eniki-amirhan/ Еники Әмирхан – Татарстан язучылар берлеге

https://yandex.ru/video/preview/2314970765239361472 Әмирхан Еники. Татар әдәбияты классигы (электрон презентация)

https://yandex.ru/video/preview/1648402267820353032 Азатлык архивы: Әмирхан Еники иҗаты

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗ МОРЗАСЫ

*(Китапханәчеләр семинары өчен якынча программа)*

**1. Ә.Еники туган һәм яшәгән чор**
*(Әдәбият белгече чыгышы).*

**2. Ә.Еникинең тормыш һәм иҗат юлы**
*(Әдәбиятка күзәтү. Чыгыш ясаучыга ярдәмлектә бирелгән әдәбият исемлегеннән файдаланырга киңәш итәбез).*

**3. Ә.Еникинең тууына 115 ел тулу уңаеннан китапханәләрдә язучының әсәрләре һәм аның турындагы әдәбият белән эшләү алымнары**
*(Методик киңәшләр).*

**4. Ә.Еникинең әсәрләрен укучыларга җиткерү буенча эш тәҗрибәсе**
*(Китапханәчеләр чыгышы).*

**5. Күрсәтмә чара.**

# ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

## Татар телендәге китаплары:

1. Еники Ә. Әсәрләр: 5 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000–2004. –

Т. 1: хикәяләр. – 447 б

Т. 2: повестьлар. – 447 б.

Т. 3: повестьлар. – 400 б.

Т. 4: истәлекләр. – 479 б.

Т. 5: публицистик язмалар, мәкаләләр. – 479 б.

2. Еники Ә. Әсәрләр: 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – Т. 1: хикәяләр, повестьлар. – 669 б.

Т. 2: повестьлар. – 555 б.

Т. 3: автобиографик роман, публицистик мәкаләләр, истәлекләр. – 838 б.

3. Еники Ә. Әйтелмәгән васыять: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр,, 2014. – 429 б.

4. Еники Ә. Без дә солдатлар идек: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 216 б.

5. Еники Ә. Биектән карап торасым килә...: заман һәм замандашларым турында. – Казан: Мәгариф, 2009. – 215 б.

6. Еники Ә. Гөләндәм туташ хатирәсе: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 184 б.

7. Еники Ә. Дус кеше: хикәя. – Казан: Татиздат, 1929. – 64 б.

8. Еники Ә. Егет кунакка кайтты: хикәяләр. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 130 б.

9. Еники Ә. Җиз кыңгырау: сайланма хикәяләр җыентыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 224 б.

10. Еники Ә. Ике матур: хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 84 б.

11. Еники Ә. Йөрәк сере: повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 110 б.

12. Еники Ә. Кояшлы иртә: хикәяләр. – Казан: Татгосиздат, 1950. – 72 б.

13. Еники Ә. Кояш баер алдыннан: публицистик мәкаләләр. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1996. – 192 б.

14. Еники Ә. Матурлык: хикәяләр, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр,, 2019. – 476 б.

15. Еники Ә. Өч повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 376 б.

16. Еники Ә. Рәхмәт, иптәшләр!: повесть. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 124 б.

17. Еники Ә. Сайланма әсәрләр: 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990–1991. –

Т. 1: повестьлар. – 463 б.

Т. 2: повестьлар. – 316 б.

Т. 3: хикәяләр. – 416 б.

18. Еники Ә. Сайланма әсәрләр: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970–1971. –

Т. 1: хикәяләр, очерклар, повестьлар. – 556 б.

Т. 2: повесть, хикәяләр, юмор, сатира. – 512 б.

19. Еники Ә. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – 468 б.

20. Еники Ә. Саз чәчәге: повесть, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. – 96 б.

21. Еники Ә. Салават күпере: хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 233 б.

22. Еники Ә. Соңгы китап: истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 504 б.

23. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 224 б.

24. Еники Ә. Хикәяләр. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 128 б.

25. Еники Ә. Чәнечкеле хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 142 б.

26. Еники Ә. Юлчы: хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 480 б.

27. Еники Ә. Ялгыз каз: хикәя. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – 15 б.

**Рус телендәге китаплары:**

1. Еники А. Глядя на горы: рассказы, повесть. – М.: Современник, 1974. – 380 с.

2. Еники А. Гуляндам: роман / пер. с татар. Р.Кутуя. – Казань: ТКИ., 1978. – 176 с.

3. Еники А. Марево: повесть, рассказы / вступ. статья Р.Мустафина. – М.: Худож. лит., 1968. – 186 с.

4. Еники А. Одно лишь слово: повести, рассказы / пер. с татар. А.Богданова. – М.: Современник, 1977. – 272 с.

5. Еники А. Повести и рассказы / пер. с татар. А.Бадюгиной. – Казань: ТКИ., 1982. – 256 с.

6. Еники А. Сердце знает: повесть, рассказы. – М.: Сов. писатель, 1963. – 144 с.

7. Еники А. Спасибо, товарищи!: повести, рассказы / пер. с татар. – М.: Сов. писатель, 1955. – 259 с.

8. Еники А. Шило в мешке: рассказы, фельетоны / пер. с татар. З.Халитовой. – Казань: ТКИ., 1967. – 83 с.

**Ә.Еники вакытлы матбугатта:**

1. Еники Ә. Ак юл сиңа, «Мирас»ыбыз!: [«Мирас» журналы тур.] / Ә. Еники, М. Мәһдиев // Безнең мирас. – 2016. – № 7. – Б. 60–61.

2. Еники Ә. Ана һәм кыз: [хикәя] // Мәдәни җомга. – 2023. – 5 май (№17). – Б.10; 12 май (№18). – Б. 10; 19 май (№ 19). – Б. 10.

3. Еники Ә. Әдип белән әңгәмә / Әңгәмәдәш М. Вәли-Барҗылы // Вәли-Барҗылы М. Күңелем кошы. – 2004. – Б. 66–82.

4. Еники Ә. Әдипнең терелеп кайтуы: Галимҗан Ибраһимов тур. // Мәдәни җомга. – 1997. – 21 март. – Б. 8 – 9.

5. Еники Ә. Әйтелмәгән васыять: [Татарстанның халык язучысы белән әңгәмә] / Ә. Еники; [әңгәмәдәш] Р. Миңнуллин // Мәйдан. Чаллы. – 2016. – № 11. – Б. 31–40.

6. Еники Ә. Әмирхан Еники белән сөйләшү: [Сәгыйть

Сүнчәләй турында әңгәмә] / әңгәмәдәш З. Рәмиев // Казан утлары. – 2019. – № 8. – Б. 181–183.

7. Еники Ә. Әмирхан ага Еники белән әңгәмә: [әдипкә 85 яшь тулу уңаеннан] / Әңгәмәдәш Мансур Вәли // Казан утлары. – 1994. – № 3.– Б. 148–157.

8. Еники Ә. Әмирхан ага ядкаре: [Әмирхан Еникинең көндәлекләреннән] // Шәһри Казан. – 2001. – 9 февр.

9. Еники Ә. Бабайлар: [хикәя] // Идел. – 2012. – № 7. – Б. 30–33.

10. Еники Ә. Балалар мәктәптә ана телендә укырга тиеш!: [1998 елның апр. язучы Ә.Еникинең мәктәп укучылары б-н очрашуы вакытында язып алынган әң-мәсе] / Әңгәмәдәш Л.Лерон // Мәд.җомга. – 2009. – 2 гыйн. – Б. 11.

11. Еники Ә. Без дә бардык Төркиягә...: Төркия тур. // Мәдәни җомга. – 1996. – 1 март (№ 9). – Б. 8–9; 8 март (№10). – Б. 8–9.

12. Еники Ә. Без кабызган утлар: [Уфада «Тулпар» исеме б-н татар телендә әдәби журнал чыга башлау уңае б-н язучылар фикере] // Тулпар. – 1994. –№ 1. – Б. 2–3.

13. Еники Ә. Безгә үлем явы килде...: язучы Ә.Еникинең фронтта алып барган көндәлек дәфтәреннән истәлекләр // Татарстан хәб. – 1994. – 7 май.

14. Еники Ә. Бер хатирә: [Казах халкының олуг язучысы Мохтар Ауэзов тууына 100 ел] // Ватаным Татарстан. – 1997. – 19 сент.

15. Еники Ә. Бөке: [хикәя] // Ватаным Татарстан. – 2009. – 16 окт.

16. Еники Ә. Гаеп кемдә?: Татарстанның халык язучысы Чечнядагы сугышка карата фикерен белдерә // Татарстан яшьләре. – 1994. – 22 дек.

17. Еники Ә. Гөмбәгә бару: [хәтер; Х. Туфан, Ф. Хөсни тур. // Казан утлары. – 1997. – № 10. – Б. 156–165.

18. Еники Ә. Дан үз вакыты белән килә ул: [танылган язучы Ә.Еники б-н 1996 елда язып алынган әң-мә] /

Әңгәмәдәш Л.Лерон // Мәдәни җомга. – 2009. – 27 февр. – Б. 9.

19. Еники Ә. Дөнья безне танысын!: [татар әдәбияты тур.] // Шәһри Казан. – 1997. – 27 авг.

20. Еники Ә. Заман анкетасы: [язучы Ә. Еники узып киткән 1998 ел тур.] // Заман-Татарстан. – 1999. – 5 гыйн.

21. Еники Ә. Замандаш сүзе: Татарстанның халык язучысы Г.Бәшировка 95 яшь // Ватаным Татарстан. – 1996. – 6 гыйн.

22. Еники Ә. Их-ма, егете!: «картаерга вакыт юк...»: [язучы Ә.Еники белән әңгәмә] / Әңгәмәдәш Ф.Фәтхи // Өмет (Уфа). – 1999. – 20 февр.

23. Еники Ә. Картлар: [хикәя] // Ватаным Татарстан. – 2021. – 12 март (№ 33). – Б. 19.

24. Еники Ә. Кем җырлады?: [хикәяләр] // Казан утлары. – 2014. – № 5. – Б. 27–30.

25. Еники Ә. Кояш баер адыннан: [сәясәт, тарих, үзгәртеп кору тур.] / // Шәһри Казан. – 1995. – 10 нояб.

26. Еники Ә. Кунакчыл дошман: [хикәя] // Безнең мирас. – 2014. – № 5. – Б. 64–75.

27. Еники Ә. Курай: [хикәя] // Аргамак. – 1999. – № 1.– Б. 23–33.

28. Еники Ә. Кырымда, Галимҗан абый янында: («Әдипнең терелеп кайтуы» исемле мәкаләдән өзек // Ялкын. – 1997. – № 3. – Б. 8–9.

29. Еники Ә. Мәк чәчәге: нәсер // Ватаным Татарстан. – 1994. – 18 нояб.

30. Еники Ә. Мандарин сатучы: [хикәя] // Ватаным Татарстан. – 2009. – 27 февр.

31. Еники Ә. Матурлык: [хикәя] // Сөембикә. – 2004. – № 4.– Б. 32–35.

32. Еники Ә. Морзалар нәселеннән ул: [шагыйрь Роберт Миңнуллинның Татарстанның халык язучысы Әмирхан ага Еники б-н әңгәмәсе] // Ватаным Татарстан. – 1999. – 2 март.

33. Еники Ә. Нәрсә ул мәхәббәт?: [язучы белән әңгәмә] // Таһир-Зөһрә. – 1999. – № 2. – Б. 2.

34. Еники Ә. Оттыру: Гата Камскийның шахмат буенча дөнья беренчелеге өчен көрәше тур. // Мәдәни җомга. – 1996. – 19 июль. – Б. 23.

35. Еники Ә. Россиянең чын йөзе: Россия сәясәте тур. язучы фикерләре // Шәһри Казан. – 1997. – 31 гыйн.

36. Еники Ә. Сау булыгыз, Тукай һәм башкалар...: [Казанның тарихи биналары язмышы тур.; [Ә.Еники әлеге язманы матбугат өчен 1969 елда әзерләгән булган, ул беркайда да басылмаган] // Ватаным Татарстан. – 2008. – 19 сент.

37. Еники Ә. Солдат төшләре: [язучының фронтта күргәннәре] // Ватаным Татарстан. – 1995. – 7 май.

38. Еники Ә. Сөйләшү чын демократик рухта үтәргә тиеш: [хәзерге көндә язучы хезмәте тур.] // Мәдәни җомга. – 1999. – 4 июнь. – Б. 3.

39. Еники Ә. Сөртенү: Фәүзия Бәйрәмова тур. // Татарстан яшьләре. – 1997. – 24 апр.

40. Еники Ә. Татарстан язучыларының XIII корылтае: [1999 ел, 28 май; язучылар корылтайга җыелды] // Казан утлары. – 1999. – № 9.– Б. 120–132.

41. Еники Ә. Татулыкны гаделлек белән тигезлек кенә саклый ала: [язучы Ә.Еники белән әңгәмә] / әңгәмәдәш А. Гарәфетдин // Заман-Татарстан. – 1999. – 19 февр.

42. Еники Ә. Тигезлек аша татулыкка: [татар һәм башкорт дуслыгы тур.] // Казан утлары. – 2009. – № 3. – Б. 122–127.

43. Еники Ә. Төп нигез: [«Соңгы китап» романыннан өзек] / Ә. Еники // Түгәрәк уен. – 2014. – № 1. – Б. 56–58.

44. Еники Ә. Утлы күмер кебек: [Г.Тукай бүләгенә кандидатлар; Әхсән Баянов иҗаты.] // Ватаным Татарстан. – 1999. – 12 март.

45. Еники Ә. Фактлар дәфтәреннән: [язучы әдәбият дөньясы кешеләре белән булган вакыйгаларны язып куй-

ган] // Казан утлары. – 2009. – №1.– Б. 154 –155.

46. Еники Ә. Фронт дәфтәреннән: сугыш чорында язылганнардан // Казан утлары. – 1995. – № 5. – Б. 117–130.

47. Еники Ә. Ходай биргән: [Илһам Шакировка 80 яшь] // Мәдәни җомга. – 2015. – 13 февраль (№ 5). – Б. 19.

48. Еники Ә. Чын дуслык: [Гыйлемдар Рамазанов тур.] // Татарстан хәб. – 1994. – 16 сент.

49. Еники Ә. Шаяру: [хикәя] // Мәйдан. – 2009. – № 3. – Б. 118–130.

50. Еники Ә. Шаяру: [хикәя] // Казан утлары. – 1999. – № 3. – Б. 55–67.

51. Еники Ә. Шәхес: [Бакый Урманченың тууына 100 ел] // Казан утлары. – 1997. – № 1.– Б. 136–140.

52. Еники Ә. Шәхес: [Бакый Урманченың тууына 100 ел тулуны каршылап] // Мәдәни җомга. – 1997. – 31 гыйн. – Б. 8.

53. Еники Ә. Шиһап абзыйның таныш кызы: [хикәя] / Авторның кереш сүзе дә бар // Сөембикә. – 1996. – № 6. – Б. 20–25.

54. Еники Ә. Юллар чатында: [эсседан өзек] // Мәдәни җомга. – 2004. – 17 дек. – Б. 10.

55. Еники Ә. Яз баласы: [повесть; гарәп язуыннан кириллицага күчерүче А.Латыйпова] // Идел. – 2011. – № 6. – Б. 42–46.

56. Еники Ә. Ялгышырга хакыбыз юк: [латин графикасына күчү тур.] // Шәһри Казан. – 1998. – 2 июнь.

57. Еники Ә. Яшьлек хатасы. // Сөембикә. – 2009. – № 3.– Б. 49–53.

## Иҗаты турында мәкаләләр:

1. Алтай Р. Татар китаплары – төрек укучысына: [Төркиядә татар әдәбияты классигы Әмирхан Еникинең хикәяләре төрекчә китап буларак дөнья күрде] // Мәдәни җомга. – 2022. – 14 гыйнвар (№ 1). – Б. 3.

2. Арслан А. Рухи матурлык җырчысы: [язучы Әмирхан

Еники турында] // Татар иле. – 2004. – № 33 (Авг.). – Б. 7.

3. Афзал Г. Хатлар: [Гамил Афзалның язучылар Нурихан Фәттахка, Нажар Нәҗмигә, Гомәр Бәшировка, Әмирхан Еникигә язган хатлары] // Мәдәни җомга. – 2016. – 27 май (№ 20). – Б. 15.

4. Баянов Ә. Күңел азатлыгы: [Ә.Еники тур. каләмдәшләре] // Казан утлары. – 2009. – № 3. – Б. 104–106.

5. Бәшир Ф. Моңнары кала икән: [Ә.Еникинең өч томлык әсәрләр җыентыгында урын алган повестьлары һәм хикәяләре турында] // Бәшир Ф. Сөйлә каләм!: әдәби уйланулар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – 2001. – Б.77–88.

6. Васильева Р. Өйнең яме ана белән: [Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясе аша балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү] // Татарстан укытучысы. – 2010. – № 1. – Б. 18–19.

7. Вәлиев Р. Әдәбиятыбыз морзасы: [ТР Милли китапханәсендә язучылар, артистлар катнашында Ә.Еникинең тууына 100 ел тулуга багышлап уздырылган кичә тур. әң-мә] / әңгәмәдәш Э.Сиражи // Мәдәни җомга. – 2009. – 12 июнь (№ 23). – Б.11.

8. Вәлиев М. Әмирхан Еники гасыры: [язучы тур. истәлекләр] // Мәйдан. Чаллы. – 2013. – № 7. – Б. 65–68.

9. Вәлиев М. Әмирхан Еники гасыры: [«Мәгариф» нәшриятында Ә.Еникинең әлегәчә китапларына кермәгән публицистик әсәрләрен үз эченә алган «Биектән карап торасым килә» дигән китабы чыкты] // Мәдәни җомга. – 2009. – 27 февр. (№ 23). – Б. 11.

10. Вәлиев Н. Әмирхан Еники: [язучы Ә.Еники (1909–2000) тур.] // Әдәби Алабуга. – 2005. – Б. 141–147.

11. Гайнуллина Г. Әмирхан Еники публицистикасында иҗат әһелләренә хас сыйфатлар турында // Фәнни Татарстан. – 2019. – № 2. – Б. 55–62.

12. Гайнуллина Г. Рәшә: [2022 елның декабрь аенда Г.Камал театры Ә.Еникинең «Рәшә» спектакле премьера-

сын күрсәтте] // Сәхнә. – 2023. – № 2. – Б. 13–20.
13. Галиев М. Соңгы могикан: [Әмирхан Еники тур.] // Татарстан яшьләре. – 2005. – 1 март.
14. Галиева Р. «Безнең эшне башка кеше эшләмәс»: [Казанда Әмирхан Еникигә истәлек тактасы ачу тантанасы тур.] // Шәһри Казан. – 2020. – 18 февраль (№ 17). – Б. 4.
15. Галиева Р. 823 километр: [Ә.Еники әсәрләре буенча төшерелгән «823 километр» кинофильмы турында] // Шәһри Казан. – 2023. – 16 май (№ 53). – Б. 5.
16. Галимова Г. «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә күтәрелгән проблемалар: [Әмирхан Еники] // Ачык дәрес. – 2009. – окт. (№ 10). – Б. 16–17.
17. Галимуллин Ф. Юк, кояш баемады...: (Әмирхан Еникинең якты истәлегенә // Татарстан. – 2000. – № 3. – Б. 50–51.
18. Галимуллин Ф. Язучы дөньясына сәяхәт: [язучы Әмирхан Еники иҗаты тур.] // Шәһри Казан. – 2009. – 20 март.
19. Галиуллин Р. «Җиз кыңгырау»: [язучы Әмирхан Еникинең тууына 100 ел тулу уңаеннан узган әдәби-музыкаль кичә тур.] // Шәһри Казан. – 2009. – 21 окт.
20. Гаррапова Р. Сүз-сурәт ясау остасы: [Ә.Еники прозасының поэтик ономастикасы] // Мәгариф. – 2008. – № 5. – Б. 85–86.
21. Гаташ Р. Әмирхан ага – әдипләр остазы...: [язучыга 90 яшь] // Ялкын. – 1999. – № 2. – Б. 15.
22. Гаташ Р. ...Бала китте бугай – шаштырды шатлык...: [Әмирхан ага Еникигә] // Казан утлары. – 2009. – № 3. – Б. 107.
23. Гаташ Р. Йолдызга ашкан рух – горур (Әмирхан ага Еникигә); [шигырь] // Татарстан. – 1995. – № 9. – Б. 53.
24. Гаффарова С. Мемуарларымның беренче өлеше – Әмирхан Еники: [өлкән язучы яшь язучының әкиятләр китабы презентациясендә була; хәтирә] // Ялкын. – 2009. – № 3. – Б. 26–27.

25. Гыйззәтуллин Н. Әмирхан ага ядкаре: [Әмирхан Еники тур. истәлекләр] // Казан утлары. – 2005. – № 1. – Б. 160–164.

26. Гыйззәтуллина Г. Әмирхан Еникинең «Матурлык» хикәясенә анализ: (VI сыйныф, татар төркеме) // Мәгариф. – 2018. – № 11. – Б. 90–92.

27. Гыйззәтуллин Н. Вәгъдәсе бар иде: [язучы Ә.Еники тур. истәлекләр] // Заман-Татарстан. – 2001. – 16 февр.

28. Гыйзәтуллина Л. «Матурлыкка омтылып, матурлыклар тудырып, яшик әле шушы дөньяда»: [Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясе буенча; VI сыйныф, татар төркеме] / Л. Гыйзәтуллина, Г. Галәветдинова // Мәгариф. – 2018. – № 5. – Б. 34–36.

29. Гыйләҗев А. ...Минем татарлыгым көчәя...: [язучы Аяз Гыйләҗевнең Әмирхан Еникигә язган хатлары] / кереш сүзне Нәкыя Гыйләҗева язган // Шәһри Казан. – 2007. – 22 июнь.

30. Гыймадова Г. Әмирхан Еникинең тууына – 110 ел: «Телне эшләтә белергә кирәк»: [Әмирхан Еникинең тууына 100 ел тулу уңаеннан узган әдәби-музыкаль кичә тур.] // Ватаным Татарстан. – 2019. – 15 февраль (№ 22). – Б. 18.

31. Гыймазова В. Әдип бәхете: [Ә.Еникинең мәхәббәт тарихы, аның тормыш иптәше һәм улы белән әңгәмә] // Мәйдан. – 2005. – № 3. – Б. 88–92

32. Гәрәева Г. Әдәбият ханы – Әмирхан: [язучы Ә.Еники иҗатына багышланган дәрес] // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2008. – № 8.– Б. 10–11.

33. Еники Ә. «Иң хәтәр вакытларда да татарның киләчәге турында борчылудан туктамадык»: [тәфсилле әңгәмә] / әңгәмәдәш Р.Юныс // Идел. – 2000. – № 4.– Б. 11–20.

34. Закирҗанов Ә. Сүз сәнгатенең әмир–ханы: [Әмирхан Еникинең тууына 100 ел] // Мәдәни җомга. – 2009. – 27 февр. (№ 8). – Б. 8.

35. Заһидуллина Д. Әмирхан Еники – төрек телендә //

Казан утлары. – 2021. – № 8. – Б. 174–175.

36. Зәйдулла Р. Еники: [язучы Ә. Еники тур.] // Идел. – 2009. – № 5. – Б. 42–44.

37. Зиннәтуллина Г. Әмирхан Еники әсәрләрендәге поэтик топонимнарның лексик-семантик үзенчәлекләре // Фән һәм тел. – 2009. – № 3–4. – Б. 22–24.

38. Зөлфәт. Асыл курай: [шигырь; Әмирхан ага Еникигә багышлана] // Казан утлары. – 1999. – № 3. – Б. 53–54.

39. Имамов В. Башкортстанга сәяхәт: [Башкортстанда яшәүче татарлар һәм Ә.Еники тур.] // Мәйдан. Чаллы. – 2013. – № 9. – Б.3–10.

40. Исмәгыйлева И. Учагында уты сүнмәсен...: [Әмирхан Еникинең тууына 100 ел тулу уңае белән хәзерләнгән әдәби-музыкаль кичә] // Ачык дәрес. – 2009. – Июнь. – Б. 25–26.

41. Йосыпова Җ. Матурлык күлмәк белән сәдәфтә генә түгел, оят белән әдәптә: [Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясен өйрәнү. 11 сыйныф] // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2002. – № 3. – Б. 46–47.

42. Камалетдинова Р. Милли рухыбыз җырчысы: [язучы Әмирхан Еникигә 90 яшь] // Сөембикә. – 1999. – № 2. – Б. 28.

43. Карташова-Еникеева Ф. Халык күтәргән әдип онытыла алмый: [Әмирхан Еникинең тууына 110 е; әдипнең кызы Флера Карташова-Еникеева б-н әң-мә] // Мәдәни җомга. – 2019. – 1 март (№ 8). – Б. 19.

44. Лерон Л. Әмирхан Еникиле заман: [язучы Ә.Еникинең тууына 110 ел (1909–2000); авторга аның белән, бик еш булмаса да, шактый вакыт аралашып яшәргә туры килә] // Мәйдан. Чаллы. – 2019. – № 3. – Б. 123–127.

45. Лерон Л. Әмирхан Еникинең Коръән китабы: [язучы турында] // Идел. – 2017. – № 12. – Б. 12–15.

46. Миңлебаева Л. Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясен өйрәнү // Мәгариф. – 1997. – № 7. – Б. 16–18.

47. Миңнуллин Р. Еники!!!: [язучы Ә.Еники тур.] // Мәйдан. – 2003. – № 9. –Б. 62–64.

48. Миңнуллин Т. Татар әдәбиятының морзасы: [Ә.Еникинең тууына 100 ел] // Мәйдан. – 2009. – № 3. – Б.116–118.

49. Мостафин Р. Солдат язмышы: [2 мартта язучы Ә.Еникинең тууына 100 ел] // Татарстан. – 2009. – № 2. – Б. 37–39.

50. Мотыйгуллина Ә. Әдип бәхете: [Әмирхан Еники тур.] // Казан утлары. – 2009. – № 3. – Б. 108–117.

51. Мотыйгуллина Ә. Әдип иҗатында милли идеянең бирелеше: [Әмирхан Еникинең тууына 110 ел] // Казан утлары. – 2019. – № 3. – Б. 176–181.

52. Мотыйгуллина Ә. Әмирхан Еники иҗатында сатира // Идел. – 2000. – №11. – Б. 60–61.

53. Мотыйгуллина Ә. Әмирхан Еникинең прототиплар дөньясы яки чынбарлыктагыча гадәти каһарманнар // Чын мирас. – 2012. – № 1. – Б. 62–65.

54. Нигъмәтуллова Р. «Ана – бөек исем!»: [Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясен өйрәнү] // Мәгариф. – 2009. – № 11.– Б. 11–12.

55. Низаметдинов З. Кырык ел үткәч...: [язучы Ә.Еники тур. истәлекләр] // Мәйдан. – 2009. – № 10. – Б. 126–136.

56. Низами Р. Әмирхан Еникидә кунакта: [язучы турында истәлек] // Казан утлары. – 2006. – № 3. – Б. 127–131.

57. Низамиева Л. Әмирхан Еникинең тормышы һәм иҗаты буенча викторина // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2000. – № 1–2. – Б.159–160.

58. Нуруллин И. Һәр хикәясе – роман: [язучы Әмирхан Еникигә – 85 яшь] // Шәһри Казан. – 1994. – 3 март.

59. Сверигин Р. Әдип тә, педагог та: [Әмирхан Еникигә – 90 яшь] // Мәгариф. – 1999. – № 2. – Б. 14–15.

60. Сөнгатуллина Н. Ә. Еники. «Матурлык»: [хикәя бу-

енча уку дәресе] // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2010. – № 2.– Б.24–25.

61. Харис Р. Әмирхан Еники иҗатының үзенчәлеге // Мәйдан. Чаллы. – 2011. – № 5. – Б. 56–59.

62. Хатипов Ф. Яшәү мәгънәсе: [Ә.Еникинең тууына – 100 ел] // Мәгариф. – 2009. – № 3. – Б. 6–9.

63. Хәйруллина Л. «Әйтелмәгән васыять» – әдип иҗатында яңа биеклек: [Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен өйрәнү] // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2009. – № 3. – Б. 7–9.

64. Хәсәнова А. Әйтелгән васыять: [танылган язучы Әмирхан Еники тур.] // Ватаным Татарстан. – 2009. – 26 май.

65. Юнысова А. Әмирхан абыйда кунакта: [Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еникинең тууына 95 ел тулу уңаеннан узган кичә тур.] // Ватаным Татарстан. – 2004. – 31 дек.

66. Янсуар Л. Әдәбиятның соңгы морзасы: [язучы Әмирхан Еники турында] // Татарстан. – 2019. – № 3. – Б. 68–73.

# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ӘСӘРЕ БУЕНЧА КИТАП УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

*Ана – бөек исем,*
*нәрсә җитә ана булуга,*
*Аналарның бөтен матурлыгы,*
*Бөтен күрке ана булуда.*

**(Һади Такташ)**

*Җиһазлау. «Ана – бөек исем», «Әмирхан Еники – күренекле әдип» дигән сүзләр язылган плакатлар, магнитофон, Ә.Еники әсәрләреннән күргәзмә, газета-журнал материаллары.*

*Максат. Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре белән танышу. Ана хакы, кешеләрнең ата-ана алдындагы бурычлары турында фикер алышу. Олыларга, туган туфракка, халкыбызның гореф-гадәтләренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.*

**1 алып баручы.** Бүген мин сезне ана хакы, ана васыяте, балаларның ата-ана алдындагы бурычы турында чын күңелдән сөйләшүгә чакырам. Бу тема кешелек дөньясы барлыкка килгәннән бирле яши, ләкин соңгы елларда әлеге мәсьәлә кискенләште, тискәре вакыйгалар кешеләрнең күңелләрен тупасландырды, җирдә шәфкатьсезлек, кешелексезлек, рәхимсезлек артты.

Без бүгенге сөйләшүне Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре белән бәйләп алып барырбыз. Кем соң ул Ә.Еники?

**2 алып баручы.** *Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты хакында сөйли.*

**1 алып баручы.** Әйе, Ә. Еникинең әдәби иҗаты югары бәяләнде. Ул Хезмәт Кызыл байрагы (1979), Почет билгесе (1957) орденнары белән бүләкләнде. 1984 елда аңа Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, 1989 елда Халык язучысы дигән исем бирелде. Бик күп әсәрләре дөнья күрде, алар тиз арада үз укучыларын тапты. Күпсанлы әсәрләре арасында үзенә аерым бер урын алып торучы әсәре – «Әйтелмәгән васыять» повесте.

**2 алып баручы.** *Әлеге әсәрнең эчтәлеге белән таныштырып китә.*

**1 алып баручы.** Әсәрнең төп герое кем? Аның хакында исегездә нәрсәләр калды?

Җаваплар тыңлана:

– Әсәрдә төп герой – Акъәби. Аның чын исеме Акбикә була. Кыз чагында – Аксылу, кияүгә чыккач – Аккилен, аннары – Акҗиңгә, ә картайгач Акъәби дип йөртәләр аны. Аның бөтен гомере Юлкотлы авылы халкы күз алдында үткән. Ул гомере буе ак, пакь күңелле булган. Шуңа күрә авыл халкы аңа җисеменә хас матур исем биргән.

– Алар гаиләләре белән Юлкотлы авылында гади генә, тыйнак кына гомер кичерәләр. Карты белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Авыл мәктәбен тәмамлагач, балаларының 4се дә шәһәргә китә, югары белем алып зур кешеләр булалар.

– Карты белән бергә яшәгәндә әби ялгызлыкны сизми, әмма карты бакыйлыкка күчкәч, әби бөтенләй ялгызы кала. Балаларын көтеп, елларын, айларын уздыра. Билгеле, әби балаларын бик ярата, алар белән горурлана, кайтмасалар, эшләре күптер, хөкүмәт кешеләре бит, дип үз-үзен юата. Аңа нәрсәдер җитми: Акъәби еллар узган саен боега бара. Моның сәбәбе нәрсәдә икән соң?

–Шәһәр тормышы белән яшәгән балалар әкренләп туган авылдан, туган туфрактан бизә. Акъәби дә, балалары белән арасы ераклашуын сизеп, бик борчыла, аларны сагына. Шәһәр белән авыл арасы 120 км гына булса да, дөньяның

әллә кайсы почмакларына барып йөрүче уллары һәм кызлары әниләре янына бик сирәк кайталар. Ялгызлыктан газапланган карчыкның кулына акча тоттырып, бурычыбызны үтәдек дип, тыныч кына яши бирәләр. Акъәбинең картлыгы җиңә, ул ныклап авырый башлый.

**2 алып баручы.** Авыргач, ни өчен соң ул тиз арада балаларын чакыртмый? Аңа нәрсә комачаулый?

Җавап:

– Башта авыруы турында балаларына белдерәсе килми. Шулай да күршеләре һәм авылның бригадиры әбинең балаларына хәбәр бирә. Кызы Гөлбикә, кияве кайтып әбине шәһәргә, врачларга күрсәтергә дип алып китәләр. Гомер иткән нигез, картының кабере ялгыз кала.

**1 алып баручы.** *Акъәбинең шәһәрдәге тормышы, авыруының көчәеп китүе турында сөйли.*

Сорау:

– Акъәби нәрсәләр турында борчыла, аны нинди уйлар бимазалый, балаларына нәрсә әйтергә тели?

– Әби авылны, аның кешеләрен, яшьлек хисләрен сагына. Ул үзенең соңгы көннәре якынлашуын сизенә. Аны иң нык борчыган нәрсә – үлсәм, мөселманча күмәрләрме икән дигән уй. Гомере буе дингә тугрылыклы булган, аның кануннарын төгәл үтәгән, балаларын да үзе үрнәгендә тәрбияләгән карчыкның күңелен шик корты кимерә. Хәле бар чагында, барысы турында да бәйнә-бәйнә сөйләп калырга тели ак күңелле әби. Аның бит үлемтеккә дип хәстәрләгән кәфенлеге, сөлгеләре, акчалары бар. Ләкин алар авылдагы сандыкта калды. Ул балаларының үлгәч үзен мөселманча итеп соңгы юлга озатуларын тели. Бары шул гына. Өстәп, әле аның балаларына, оныкларына дип саклап торган истәлекле киемнәре, затлы бизәнү әйберләре бар, аларның һәрберсен атап әйтеп калдырасы килә. Ә балаларының тыңларга вакытлары юк, алар каядыр ашыгалар, ашыгалар, ашыгалар... Әбинең соңгы көннәре якынлаша, ул ты-

ныч кына, сабыр гына үлемен көтеп ята. Күңелендәге өмет чаткысы сүнеп бетмәгән әле, хәле җиңеләюгә, кызын янына утыртып, тагын үзенең соңгы сүзен, соңгы васыятен әйтеп калырга ашыга. Инде кызы әнисенең сүзен тыңлап бетерер, әнисенең васыятен үтәргә сүз бирер дип өметләнә укучы җаны. Акъәби дә тыныч күңел белән фани дөньядан бакыйлыкка күчәр, дип көткәндә, юк шул, кызы тагын сәбәп табып әнисе яныннан торып китә. Васыять әйтелмичә кала, әби аны үзе белән кабергә алып китә.

**2 алып баручы.** *Шушы урында әбинең газиз балалары, аларның тормышлары, нинди һөнәр иясе булулары турында сөйли.*

**1 алып баручы.** Сезнеңчә, балалар нәрсә эшләргә тиеш иделәр?

Минемчә, алар, беренчедән, җыелып, җитди итеп сөйләшергә, ничек кенә булмасын, әниләренең сүзен тыңлап бетерергә, анага борчылырлык урын калдырмаска тиеш иделәр. Бигрәк тә кызлар әниләргә якын, әни җанлы буырга тиеш, дип уйлыйм мин. Әгәр дә әбине мөселманча итеп, бөтен шартын китереп җирләсәләр, үзләренә дә рәхәт, күңелләре тыныч булыр иде. Балалары аны авылга алып кайтып, әтиләре янына күмәргә тиешләр иде. Әниләренең сүзен берәрсе булса да тыңлап бетерсә, мондый рәхимсезлеккә бармаслар иде. Ә бит алар әтиләре алдындагы бурычларын да үтәмәгәннәр, хәтта аның каберен дә белмиләр. Акъәби уйлаганча әйтсәк, «Машиналар сатып алырга хәлләреннән килә, әтиләренең кабеернә бер таш яздырып куярга хәлләреннән килми».

– Балаларның кыланмышлары бездә авыр хисләр уята. Адәм баласы укып кына, зур уку йортлары тәмамлап кына чын кеше була алмый икән шул әле. Кеше дигән исемне йөртәсең икән, син иң беренче кешелекле, шәфкатьле, миһербанлы булырга тиешсең. Әби шулай ук ялгызмыни соң? Аның күңелен аңларлык, аның белән чын күңелдән

сөйләшерлек кешеләр булмады микәнни янында?

**2 алып баручы.** *Акъәбинең авылдашлары, шагыйрь егет, Гөлбикәнең кызы белән улы турында сөйли.*

**1 алып баручы.** Ә хәзерге көндә әби-бабайларның язмышы ни хәлдә? Акъәби язмышына дучар булган картлар турында ишеткәнегез юкмы?

*Укучыларның чыгышлары.*

**2 алып баручы.** Әйе, Әмирхан Еники безгә бу әсәре белән кешеләрнең күңелләре тупаслануын, җир йөзендә мәрхәмәтсезлекнең тамыр җибәрүен 1965 елда ук искәрткән. Аналар алдында барыбыз да бурычлы. Без әле аны аңлап бетермибез. Ә элегрәк кешеләр ярлы яшәсәләр дә, күңелләре бай, ата-анага хөрмәте зур булган. Уллары булган ата-ана һич тә ялгызлык кичермәгән, чөнки малай кеше әти-әнисен карарга, төп йортта калырга тиеш булган. Балалар ата-ана каргышыннан курыкканнар. Бер генә мисал китерәм. Халкыбызның «Сак-Сок» бәете мәдрәсә дәреслеге булып торган. Ә анда ана каргышы алган бәхетсез балалар турында сүз бара. Шушы әсәрне халкыбыз көйгә салып укыган, ятлаган, балалар күңеленә сеңдергән. Мин сезгә аның кайбер юлларны гына укып китәм. Минемчә, әсәрнең әһәмияте хәзерге көндә әйтеп бетергесез. Аны укып чыккан кеше һичкайчан ата-анасы алдындагы бурычын онытмас, дип уйлыйм мин.

**1 алып баручы.** Кадерле яшь дусларым! Чыннан да, без бүген сезнең белән күтәргән мәсьәлә бик әһәмиятле. Бу сөйләшү күңелләрегезгә барып җитеп, киләчәктә әти-әниләрегез алдындагы бурычыгызны үти алсагыз, мин бик шат булыр идем. Ә хәзер бергәләп Р.Миңнуллин сүзләренә М.Шәмсетдинова язган «Әни кирәк» җырын җырларбыз. Көннәрегез имин, күңелләрегез саф, җаныгыз инсафлы булсын!

# ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ БАГЫШЛАНГАН ШИГЫРЬЛӘР

1. Әхмәтҗанов Р. Гасырларда яшәр юксыну (Әмирхан ага Еники ядкаре) // Казан утлары. – 2000. – № 11. – Б. 42.

2. Гаташ Р. Йолдызга ашкан рух – горур (Әмирхан ага Еникигә) // Татарстан. – 1995. – № 9. – Б. 53.

3. Гаташ Р. Әмирхан ага Еникигә // Казан утлары. – 1996. – № 2. – Б. 91–92.

4. Зөлфәт. Асыл курай // Казан утлары. – 1999. – № 3. – Б. 53–54.

5. Идиятуллин Р. Әйтеп китәсем килә (Әмирхан ага Еникигә) // Казан утлары. – 1997. – № 9. – Б.74–75.

6. Кәримов М. Әмирхан Еникигә: [шигырь] // Чын мирас. – 2014. – № 3. – Б. 75.

7. Нәзиров М. Күпер (Әмирхан ага Еникигә) // Казан утлары. – 1999. – № 9. –Б. 112–116.

8. Нәҗми Н. «Тискәреләр» (Әмирхан ага Еникигә) // Казан утлары. – 1999. – №3. – Б. 49–50.

# ӘМИРХАН ЕНИКИ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ, КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

**Фатих Хөсни:**

Әмирхан Еники турында сүз әйтү бер үк вакытта читен дә, рәхәт тә. Читен, чөнки ул – бик катлаулы, үтә дә нечкә күңелле художник. Әйтә белмичә әйтсәң, тота белмичә кулдан төшереп ваткан хрусталь ваза кебек, аның иҗатын чәлпәрәмә китерүең дә мөмкин. Рәхәт, чөнки аның иҗаты уйланырлык азык, күңелгә шатлык, колакка музыкаль аһәң бирә.

... Яшь, зифа буйлы, кара чәчле, мөлаем егет, ул әдәбиятка ничектер кыяр-кыймасрак килеп керде һәм хәзергә хәтле, башы пеләшләнә башлагач та, уннарча повесть һәм бик күп талантлы хикәяләр авторы булгач та, безнең барыбызның да, иң әһәмиятлесе, киң катлау укучыларның ихлас мәхәббәтен

казанганнан соң да, шулай кыяр-кыймас кына барган кебек. Аның бу тыйнаклыгы үзенең көчен белмәгәнлектән түгел, юк, ул үзенең әфсенле көчен бик яхшы белә, аның бу тыйнаклыгы халык алдыңдагы бурычын тирәнтен аңлавыннан. Юк, әдәбият уйнар өчен түгел, әдәбият дан казану, акча эшләү мәйданы да түгел, әдәбият – энә белән кое казу, әдәбият – кеше күңелен тәрбияләү, әдәбият кешеләрне яхшы булырга, көннән көн яхшырак була баруга этәрү коралы. Без менә шул бөек бурычны үтибезме? Барыбыз да бертигез үтибезме? Әмирханның тыйнаклыгы, минемчә, әнә шул сораулардан килеп туадыр кебек.

... Гомумән, Әмирхан Еники иҗаты өчен иң күренекле сыйфат: ул да булса аның әсәрләрендә, бөтенесендә, әлбәттә төрлесендә төрле дәрәҗәдә, кеше җанының хәрәкәткә килүе. Ясалма конструкцияләргә чуар бизәкле какшау бина корудан ерак тора Әмирхан. Аның әсәрләрендә – бөтенесендә дә – җанлы кешеләр, уйлана, газаплана һәм шатлык кичерә белә торган кешеләр яши! Әмирханның укучыны сихерли ала торган көче нәкъ әнә шунда да инде.

Әмирханны үзенчәлекле художник итеп танытkan хосусиятләрнең тагын берсе – аның теле. Аның хикәяләрен, повестьларын укыганда телебезнең нинди көч-кодрәткә ия булганлыгын янә һәм янә бер кат төшенәсең. Логик эзлеклелек, сүз асты дөньясының тигез һәм тыныч агышы, нәкъ үз урыннарына утырган сүзләрнең, берсе икенчесеннән көч алып, музыкаль аһәңлелек белән җырлап торулары – боларны һәм әйтәм дигәндә телгә килмәгән башка күркәм якларны, беренче нәүбәттә, нәкъ менә Әмирхан иҗатыннан табабыз.

«Табабыз» – урынлы әйтелмәде. Аларны эзләргә кирәк түгел, алар әсәрнең тукымасында, алар – тасвирлана торган хәл-әхвәлләрнең мускулы, эчке пружинасы буларак, укучыны шундук эләктереп алалар һәм алып китәләр. Бу тасвирның әфсененә бер эләктеңме, ычкынырмын димә. Ул

сине тирбәтеп һәм моңландырып, уйланырга һәм тормыш, көнкүреш картиналарына үз күзең белән карарга мәҗбүр итеп, алып бара, алып бара...

...Кыскасы, безнең Әмирханыбыз, безнең нечкә һәм сизгер күңелле, коеп куйган художнигыбыз, Әмирхан Еникиебез бар. Ул безнең арада, безнең белән иҗат итеп, бергә шатланып, бергә борчылып, дөньяга һәм кешеләргә бәхет-сәгадәт теләп яши. Аның бәйрәме безнең дә бәйрәм!

*1979 ел*

**Фәрваз Миңнуллин:**

Күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли аның әсәрләре... Гүяки алар каләмне язу карасына түгел, ә бәлки хискә – моңга-сагышка манып язылганнар. Аның әсәрләрендә, моңсагыш белән бергә, сине сафландыра һәм пакьләндерә торган, сине баета, зур эшләргә дәртләндерә һәм канатландыра торган рухи көч тә бар...

Шуңа да җаныңны кая куярга белми бәргәләнгәндә кулыңа Ә. Еники әсәрләрен аласың.

Укыган саен укыйсы килеп тора аның әсәрләрен. Күбрәк укыган саен, иҗатының сихри көченә соклану хисе арта, шуның сәбәпләрен беләсе, ачасы килү теләге көчәя. Шуның белән бергә, тормышның үзе кебек үк гади һәм табигый, тормышның үзе кебек үк катлаулы да аның иҗаты. «Туган туфрак», «Яшьлек хатасы» кебек бер-ике әсәрен санамаганда, Еники әсәрләренең идеясе бервакытта да «мин монда!» дип, алга чыгып кычкырып тормый. Идея образга тәмам сеңеп, аңа кушылып, эреп беткән була. Язучы укучы аңына юлны аның йөрәге аша сала белә. Бу – бары олы художникларга гына хас бер сыйфат булса кирәк.

*1983 ел*

**Илдар Юзеев:**

Язучының үзенчәлекле хикәяләү алымы халыктан килә:

әйтерсең, син якын дустың белән чәй эчеп утырасың, ул сиңа бер дә кабаланмыйча гына, көндәлдәге йөгәнсез дәртне тыштан яшерә-яшерә, күзенә бәреп чыгарга торган яшь бөртеген эчкә йота-йота, сөйли. Ул сөйли, ә син күпне күргән, күпне кичергән бу тылсым иясенең авызына карыйсың да, аның сихри сөйләме артыннан иярәсең. Сөйли генә түгел, көйли дияр идем мин. Прозасының шагыйранә үз ритмы бар. Иренгә тидерүгә көй уйный башлаган ялан курае сыман, сөйләме табигый, иркен ага. Ул сөйли, ул сиңа халыкның катлаулы язмышын, тугрылыгын, вөжданын, мәхәббәтен тасвирлый. Син тыңлыйсың һәм татар халкына гына хас булган кабатланмас милли характерларны, ерак бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне, этнографияне күзаллыйсың.

*1978 ел*

**Рафаэль Мостафин:**

Әмирхан Еники – хикәягә ифрат зур җаваплылык хисе белән килә торган искиткеч таләпчән язучыларның берсе. Художник буларак аның төп үзенчәлеген бер сүз белән әйтеп бирү соралса, мин бер дә арттырмыйча, татар әдипләре арасында ул иң музыкаль язучы, дип җавап бирер идем. Аның фразалары һәрвакыт җиңел, үтә күренмәле, музыкаль яңгырашлы. Хикәяләре, әйтерсең лә, ниндидер бер сихри көчкә, тылсымга ия, аларның һәркайсы укучыда билгеле бер настроение уята. Еш кына очракларда хикәяләүдәге якты, җиңелчә моңсулык әбиләр чуагының көмеш пәрәвезләре сыман зәңгәр һавада тирбәлеп тора сыман.

Ә. Еники – менә дигән тел остасы һәм бик сизгер стилист. Аның әсәрләренең русча тәрҗемәләрен укыганда, мин, мәсәлән, үземне бик кыен хәлдә калгандай хис итәм. Юк, тәрҗемәләрнең ул чаклы ук начар сыйфатлы булулары өчен түгел. Бу язучы татар теленең үзенә генә хас стихиясе, милли фикерләүнең, дөньяны танып-белүнең татар кешесенә хас булган үзенчәлекләре белән шулкадәр тыгыз бәйләнгән ки, иң

әйбәт эшләнгән тәрҗемәдә дә ниндидер югалтулар котылгысыз. Еникинең Бөтенсоюз укучысына чагыштырмача аз билгеле булуын да бәлки әнә шуның белән аңлатырга кирәктер. Югыйсә бит, аның иҗат багажында иң өлгереп җиткән теләсә кайсы әдәбият укучысын да сокландыра алырлык «Бер генә сәгатькә», «Ялгызлык», «Әйтелмәгән васыять», «Тынычлану» һәм башка хикәяләр бар.

Прозаикның оригинальлеге барыннан да элек аның фикерләвенең оригиналь булуында. Художестволы фикерләү! Әмирхан Еники хикәяләренә анализ ясагач, менә шундый нәтиҗәгә киләсең. Еникидә бернинди әзер чишелеш юк, тормышны ул әдәби схемаларга «куып» яки көчләп кертергә тырышмый. Ул үз идеясен турыдан-туры тәгъбирләүдән кача, үз мөнәсәбәтен теге яки бу персонажга бәйләргә теләми. Нәтиҗә ясауны укучының үзенә калдырып, теге яки бу күренешне гаделлек, риясызлык һәм объективлык белән сурәтли. Менә шуның өчен дә аның күпчелек әсәрләре бәхәсләр һәм капма-каршы фикерләр көрәше китереп чыгара.

Ә. Еники башлыча кешенең эчке дөньясы, аның хисләре, мораль һәм әхлакый сфера белән кызыксына. Аның әсәрләрендә турыдан-туры күзгә ташланып торган «производство конфликтлары» да, көннең кадагына ашык-пошык кына «сугу» да юк. Әмма алар кешеләргә тирән мәхәббәт белән сугарылганнар, кеше күңелендәге иң яхшы, иң матур якларга мөрәҗәгать итүгә юнәлдерелгәннәр.

Язучы матурлыкны, ул тышкы ямьсезлек һәм хәтта гариплек артына яшеренгән булса да, тоя һәм күрә белә. Беренче карашка кечкенә, әһәмиятсез булып күренгән нинди генә вакыйга турында язмасын, Еники ул һәрчак күренешнең асылына төшенергә, фактның фәлсәфи мәгънәсен ачып бирергә тырыша.

*1979 ел*

**Әхсән Баянов:**

Минем өчен таянырлык рәтле кеше иде ул. Үзе дә мине шулай санагандыр дип уйларга җөрьәт итәм. Чөнки «Юлчы» дигән җыентыгының титул битенә шул хакта язган иде. Халык өчен ул исән чагында ук тере классик булды. Гәрчә аның да иҗат юлы шома гына була алмады. Тәнкыйтьчеләрнең тискәре мөнәсәбәтенә түзеп яшәде ул. «Рәшә» повесте чыккач, «Кояшлы язны рәшә капламасын» (К. Фәсиев) дигән мәкаләдән соң тискәре мөнәсәбәт аеруча көчәеп китте. Авторитар тәнкыйтьнең бертуктаусыз изүенә карамастан, кеше үз мәслəген үзгәртмәде. Үтә кызыл әсәрләргә таба борылмады.

Ул «иҗат азатлыгы» дигән сүзләрне еш кабатлый иде. Миңа карата да әйткән сүзләрен хәтерлим. «Дөньяны үзең күргәнчә тасвирлау хокукы». Бик тырышсалар да, аны шул хокуктан мәхрүм итә алмадылар.

Ә. Еникинең барлык уңышлары әхлакый ныклык белән аңлатыладыр дип уйлыйм. Элек классик булган кебек, ул хәзер дә тере булып кала. Теге вакытта ук язылган шедеврларын укып карагыз. Аларда җанга кагылышсыз бер генә җөмлә, бер генә сүз дә таба алмассыз. Чөнки аның иҗаты чит тәэсирләрдән азат. Яза башлаганда ук ул чиста күңелле кешеләрне сайлаган.

Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники милләтебезгә барыннан да элек әнә шушы сыйфатлары белән кадерле. Какшамас иманы белән зур ул, бөек ул!

**Туфан Миңнуллин:**

Сүзне үземнән башлыйм әле.

«Канкай углы Бәхтияр» драмасын язганда патшабикә Екатерина II белән граф Потёмкин диалогын язарга кирәк иде. Әллә ничә вариант язып карадым–үземне канәгатьләндермәде. Авыл апасы белән авыл агаеның сөйләшүе килә дә чыга. Бик озак азаплангач кына үз дигәнемә ирештем шикелле.

Әмирхан ага Еники турында уйланганда әлеге вакыйганың

искә төшүе очраклы түгел. Безнең бик күп әсәрләребездә әдәби осталык нык аксый. Югыйсә, барысы да урынында кебек, ләкин нидер җитеп бетми. Нидер дигәнем – әйтәсе фикерне төгәл, саллы һәм, иң әһәмиятлесе, нәзакәтле, нәфис итеп әйтә белү осталыгыдыр.

Әмирхан Еники дә бит без язган, без кулланган сүзләрдән төзи җөмләләрен. Нигә аны укып сокланабыз да, кайберләребез язганның өч-дүрт җөмләсен укуга ук күңел кайта? Уңмаган хатынның оешып бетмәгән коймагын ашап интеккән кебек.

Мөхәррирләрдән ишеткәнем бар: Әмирхан Еники редакцияләргә китергән кульязмаларын басылып чыгар көнгәчә төзәтә, камилләштерә иде, диләр. Димәк, Әмирхан ага уз иҗатына олы хөрмәт һәм җаваплылык белән караган.

Әйе, ул үз иҗатының гына түгел, тулаем татар әдәбиятының затлылыгын билгеләүче язучы иде.

**Нажар Нәҗми:**

Әмирхан Еники минем өчен – тере классик, матур сүз остасы. Әйтер идем, ул проза белән яза торган шагыйрь. Аның әсәрләре – кеше йөрәгенә ята торган әсәрләр. Моңа ул табигате белән нечкә күңелле, кешелекле булуы белән ирешә. Шул яклап ул миңа өлкән дус та, остаз да.

*1994 ел*

**Рабит Батулла:**

Әмирхан Еники язучы гына түгел, ул – әдип. Ул – акыл иясе, Ана теле сагында торучы, халкы-милләте турында киеренке уйланучы, халыкның азатлыгы өчен көрәшүче, шул көрәшнең ысулы итеп әдәбият мәйданына чыккан баһадир. Әмирхан Еники гомере буе шул гамәлдә булды.

...Соңгы 30-40 ел эчендә язылган чәчмә әсәрләрдә шигырьдә булган затлылык сирәк очрый. Әмма Әмирхан Еники әсәрләрендә бу сыйфат аерым урын тота. Аның

әсәрләрен син кайта-кайта укыйсың, укыган саен яңа нәрсә ачасың. Әдипнең серле кинаясе сиңа, Сим-Сим ачкан серле ишек кебек ачылып китә. Шигырьгә тиң хикәя әнә шулай берничә катламнан торырга тиештер инде ул.

...Хәсән Туфан Фатих Әмирхан турында: «Әдәбият ханы – Әмирхан» дип язган иде. Әмирхан Еники турында мин дә шул сүзләрне кабатлыйм: Әдәбият ханы – Әмирхан!

**Равил Фәйзуллин:**

– Әмирхан ага – гомере буе үз гамәленә үзе хуҗа булган зат. Сабыр-тыйнак кына, кабаланмыйча, очар биеклекләрне анык белеп, узгынчы сәяси-конъюнктур хәрәкәтләрдә буталмыйча, талантының кодрәтен, шәхес буларак үз дәрәҗәсен белеп яшәде, иҗат итте. Бу очракта чыгышы ягыннан мәгълүм ыру-токымнан, затлы нәселдән булуы да шактый ук әһәмиятле булса кирәк.

Һәр иҗатчы, телиме-теләмиме, таныймы-танымыймы, ул – барыбер Вакыт галиҗәнаплары белән алышка чыккан зат. Чарасызлыкны, Вакыт кодрәтенә беркемнең, бернәрсәнең дә каршы торалмаганын белсә дә, Иҗатчы, Вакытның «ялына ябышып булса да», хезмәтләре белән Аңа үз исеме белән мөһер суга... Киләчәктә Идел-Урал тирәлегендә XX гасырның төрки прозасы турында сүз чыкса, иң беренчеләрдән булып Ә. Еники исеме телгә алыначак. Иҗаты һәм яшәү рәвеше белән килер буыннарга, бигрәк тә каләм ияләренә, бик тә кирәк әхлакый сабаклар да бирде Әмирхан агабыз. Шуларның берсе (гәрчә аксиома кебек мәгълүм булса да) – язучы нинди генә заманда, нинди генә шартларда яшәп иҗат итсә дә, вөҗданына тугры калып, көндәлек мәшәкатьләрдән өстен торып, тормыш дөреслеген язарга тиеш.

Бу – Аның язучылык кредосы иде, күпләр өчен өлге булыр сыйфаты. Тагын икенче бер гыйбрәтле сабак-нәтиҗә: хикәяләү, тасвирлау шигырь рухы белән сугарылмаса,

чәчмә әсәр шигъри телле булмаса, чын проза әсәре юк ул. Әмирхан Еники – прозаның шагыйре ул.

Әмирхан Еники исән чагында данда коенып, иҗатына тиереннән артыгын алган (андыйлар да булды!) язучы түгел. Чын бәһасе киләчәктә алыначак әдип ул. Әмирхан учагы әле дөрли генә башлады.

**Марсель Галиев:**

Әдәбиятта асыл бәя язучы мирасының күләменә, күплегенә карап түгел, ә чын сәнгати әсәрләрнең сыйфат дәрәҗәсен күзаллап, татар әдәби теленең бөеклеген раслаган, милләтнең гореф-гадәте, гаме аша әрнүен дә, омтылыш-кичерешләрен дә югары кимәлдә тасвирлап, рухи хәзинә тудыра алганнарга бирелергә тиеш. Мондый бөек затларыбызның берсе – Әмирхан Еники.

**Мансур Вәли-Барҗылы:**

Әмирхан Еникине мин татар халкының иң зур әдибе дип саныйм.

Аның әсәрләренең гаҗәеп дәрәҗәдәге фәлсәфи тирәнлеге, әдәби-эстетик яктан үтә камиллеге, аларда милли рухның һәм милли психологиянең гаять нечкә һәм матур чагылышы, тормыш күренешләренең бик тә масштаблылары һәм типиклары сайлап алыну һәм тасвирлану, әсәрләрнең халык моңнарына якын дәрәҗәдә музыкаль янгырашы һәм әдәбият-сәнгать әсәрләре өчен хәлиткеч кимәлдә мөһим булган тагын башка асыл сыйфатлар безгә Әмирхан Еники иҗатына әнә шундый иң югары бәһане куюю мөмкинлеге бирә.

## ВИКТОРИНА ҮТКӘРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

**1. Әмирхан Еники кайчан һәм кайда туган?**
*(1909 елның 2 мартында Башкортстан АССРның Благовар районы Каргалы авылында)*

**2. Аның балалык һәм мәктәп еллары кайда үтә?**
*(Күчеп китү сәбәпле, Дәүләкән авылында)*

**3. Ул кайчан Казанга килә?**
*(1925 елда)*

**4. Әмирхан Еникинең беренче иҗат җимешләре нинди жанрда язылган?**
*(Әдәби парчалар һәм хикәяләр)*

**5. Бөек Ватан сугышында катнашканмы?**
*(Катнашкан)*

**6. Әмирхан Еники ничәнче елдан профессиональ язучы?**
*(1953 елдан)*

**7. Әмирхан Еникигә кайчан һәм нинди әсәре өчен Г.Тукай премиясе бирелә?**
*(1984 елда «Юлчы» хикәяләр җыентыгы һәм «Повести и рассказы» китаплары өчен)*

**8. Ул ничәнче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы?**
*(1946 елдан)*

9. **Бу өзекләр әдипнең кайсы әсәрләреннән алынган?**
*«Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына*

*кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә ке-бек алар...»*
*(«Әйтелмәгән васыять»)*

*«Безнең эшелон станциядә, эти... Без госпитальдән фронтка китеп барабыз. Поезд бераз торасы булганга, мине менә сезнең белән күрешеп чыгар өчен бер генә сәгатькә җибәрделәр»*
*(«Бер генә сәгатькә»)*

*«Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон эченә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә чыннан да бу егетнең сөйгәне Таһирә иде»*
*(«Кем җырлады»)*

10. **Ул ничәнче елдан Халык язучысы?**
*(1989 елдан)*

11. **Әмирхан Еники татар халкының атаклы композиторы Салих Сәйдәшевнең яшьлеген кайсы әсәрендә сурәтли?**
*(«Гөләндәм туташ хатирәсе»)*

12. **Язучының әсәрләре кайсы телләргә тәрҗемә ителгән?**
*(Рус, украин, үзбәк, казакъ, башкорт, чуваш һ.б.)*

13. **Бакый Урманченың тууына 100 ел тулу уңаеннан язучы нинди әсәр язды?**
*(«Шәхес»)*

14. **К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Әмирхан Еникинең нинди әсәре буенча спектакль куелды?**
*(«Гөләндәм туташ хатирәсе»)*

15**. Язучының «Соңгы китап» әсәре нинди жанрда язылган?**

*(Автобиографик повесть)*

16. **Г. Камал театры Ә. Еникинең нинди әсәреннән һәм кайчан спектакль сәхнәләштерде?**

*(2022 елның декабрь аенда «Рәшә» спектакленең премьерасын чыгарды)*

17. **Аның кайсы әсәрләре буенча нинди кинофильм төшерелде?**

*(«Матурлык», «Кем җырлады», «Бер генә сәгатькә» әсәрләре буенча «823 километр» фильмы)*

# ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ СҮЗ ........................................................................ 3

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ МОРЗАСЫ
*(Китапханәчеләр семинары өчен якынча программа)* ....... 8

ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ .............. 9

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ
«ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ӘСӘРЕ БУЕНЧА
КИТАП УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ .................... 22

ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ
БАГЫШЛАНГАН ШИГЫРЬЛӘР *(Исемлек)* .................. 27

ӘМИРХАН ЕНИКИ ТУРЫНДА
ЗАМАНДАШЛАРЫ, КАЛӘМДӘШЛӘРЕ ..................... 27

ВИКТОРИНА ҮТКӘРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР .................. 36

Басарга кул куелды 28.03.2024. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 75 данә. Заказ № 479.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе,
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86 йорт.

Подписано в печать 28.03.2024. Формат 60x84 1/16.
Тираж 75 экз. Заказ № 479.
Национальная библиотека Республики Татарстан,
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, д. 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.
420015, Казан шәһәре, К. Маркс ур., 36 йорт.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420015, г. Казань, ул. Карла Маркса, д. 36.